РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ БОЛЬШЕШИНАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422054, Республика Татарстан,
Сабинский район,с.Большой Шинар,
ул. Кооперативная,дом 36
тел. (84362) 41-2-11

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422054, Татарстан Республикасы,
Саба районы,Олы Шыңар авылы,
Кооператив урамы, 36 йорт
тел. (84362) 41-2-11

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

---

РЕШЕНИЕ — КАРАР
17.12.2025 — №14

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 2018 нче елның
30нчы апрелендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге
җирле үзидарә органнарының депутатларына,
сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль
хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары
турында Нигезләмә " турында 9нчы номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында»

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 25.11.2025 елгы № 994 “ Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең, муниципаль хезмәткәрләрнең, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторларының хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.03.2018 ел; №182 карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә Олы Шыңар авыл җирлеге советы карар бирә:

1.«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмә»нең 30.04.2018 елгы № 12 карарына (Советның 09.11.2020 ел №12; 17.11.2022 ел №15; 19.12.2022 №20, 13.11.2024 №26, 25.04.2025 № 11 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:
«2. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгече вазифа окладын 16928 сум күләмендә расларга.»;
1.2. 1нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә, әлеге карар өчен 1нче кушымта нигезендә җиткерергә.
2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына, әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә

алып, 2026 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә булу башлангач, яңа штат расписаниеләрен расларга.

3. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү, тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4. Әлеге карар 2026нчы елның 1 гынварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru һәмТатарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/shinar адреслары буенча бастырып чыгарырга.

Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы А.Г.Гарипов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Олы Шыңар авыл җирлеге Советының
2025елның 17нче декабре,
14нче номерлы карарына
1 нче кушымта

Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының акчалата бүләк күләме

| Вазыйфалар исемнәре | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Авыл җирлеге башлыгы | 25 401,00 |
| Депутатлар | 16 928,00 |
| Сайланулы вазыйфаи затлар | 16 928,00 |